СОВЕТ
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

13.12.2019 Әгерҗе шәһәре № 42-2

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы бюджетыннан авыл җирлекләре бюджетларына хәрби комиссариатлары булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләрне тормышка ашыру өчен субвенцияләр бирү Кагыйдәләре турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142нче статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Кушымта итеп бирелгән хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләрне тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы бюджетыннан авыл җирлекләре бюджетларына субвенцияләр бирү Кагыйдәләрен расларга.

2. Әлеге карар 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча: http://agryz.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (игълан итәргә).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының Бюджет, салымнар һәм финанслар буенча Даими комитетына йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы,
Совет рәисе В.В. МАКАРОВ

РАСЛАНГАН
Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Советының 13.12.2019 № 42-2
Карары белән

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы бюджетыннан авыл җирлекләре бюджетларына хәрби комиссариатлары булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләрне тормышка ашыру өчен субвенцияләр бирү Кагыйдәләре

1. Әлеге кагыйдәләр Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы бюджетыннан авыл җирлекләре бюджетларына хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен субвенцияләр бирү максатларын, тәртибен һәм шартларын билгели.

2. Субвенцияләр хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру вәкаләтләрен гамәлгә ашыру максатларында җирлекләр бюджетларына бирелә.

3. Җирлекләр бюджетларына субвенцияләр бирү чыгымнарын финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы булып Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы бюджетына бирелә торган хәрби комиссариатлары булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен федераль бюджеттан субвенция тора.

4. Әлеге кагыйдәләр нигезендә бирелә торган бюджет акчаларын баш бүлүче булып Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба-Башкарма комитет) тора.

5. Җирлек бюджетына субвенция күләме «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына җирлекләр бюджетларына субвенцияләр исәпләү һәм бирү буенча Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2006 елның 11 декабрендәге 78-ТРЗ номерлы Законга 1 нче кушымта нигезендә, хәрби комиссариатлары булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләрне тормышка ашыру өчен муниципаль район составына керүче җирлек бюджетына муниципаль район бюджетыннан субвенция күләмен билгеләү методикасы нигезендә билгеләнә;

6. Муниципаль район составына керүче җирлекләр бюджетларына субвенцияләрне бүлү тиешле финанс елына һәм план чорына муниципаль район бюджеты турында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы карары белән раслана.

7. Субвенцияләр җирлекләрнең бюджетларына тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм Башкарма комитетка әлеге Кагыйдәләрнең 2 пунктында каралган максатларга билгеләнгән тәртиптә бирелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

8. Субвенцияләр түбәндәге чыгымнарны гамәлгә ашыру өчен җирлекләр бюджетларына бирелә:

хезмәткә түләү фондына тиешле түләүләрне дә кертеп, хәрби-учет хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү;

биналарны арендалау өчен түләү;

элемтә хезмәтләре өчен түләү;

транспорт хезмәтләре өчен түләү;

командировка чыгымнары;

коммуналь хезмәтләр өчен түләү;

җиһаз, инвентарь, оргтехника, элемтә чаралары, чыгым материаллары белән тәэмин итү.

9. Субвенцияләрне тоту Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең территориаль органнарының (алга таба – Казначылык) җирлек бюджетлары үтәлешенә касса хезмәте күрсәтү өчен ачык булган шәхси счетлары аша башкарыла.

10. Башкарма комитет Казначылыктан финанслауның иң чик күләмнәрен билгеләү өчен чыгым расписаниесен алганнан соң җиде эш көне эчендә Казначылыкка субвенцияләр исәбеннән җирлекләр бюджетларына субвенцияләр күчерү өчен касса чыгымына гариза бирә.

11. Җирлекләрнең җирле үзидарә органнары хисап чорыннан соң килүче айның 5 числосыннан да соңга калмыйча Башкарма комитетка хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә финанс тәэминаты чыганагы субвенция булган территорияләрдә Россия Федерациясе Оборона министрлыгы белән килешү буенча Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән форма буенча җирлекләр бюджетлары чыгымнары турында хисап тапшыралар.

12. Башкарма комитетка тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеге өчен җаваплылык җирлекләрнең җирле үзидарә органпарына йөкләнә.

13. Субвенцияләр бирү шартларын бозган очракта, тиешле акчалар Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә муниципаль район бюджеты керемена күчерелергә тиеш.

14. Субвенцияләр бирү елыннан соң, килүче елның 1 гыйнварына кулланылмаган субвенцияләрнең калган өлеше, Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән таләпләр нигезендә, муниципаль район бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

15. Субвенцияләр максатчан характерга ия һәм, әлеге Кагыйдәләрнең 2 пунктында күрсәтелгәннәрдән тыш, башка максатларда кулланыла алмый.

16. Субвенцияләрнең максатчан кулланылышын закон нигезендә Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районы Башкарма комитеты һәм финанс органы контрольдә тота.